# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Үрәзмәт авыл жирлеге Чишмә торак пунктында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында

21 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар жыены нәтиҗәсе белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000(ике мең) сум күләмендә, 1 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 1000(бер мең) сум күләмендә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизациялэнгэн гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
-Урам яктырткычларын тоту, яктылык диодлы яктырткычлар сатып алу;
- Ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту: агачларны кистем, үләнне чаптым;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге: юлларны ремонтлау, юлларны җәй һәм кыш айларында карап тору, юл буендагы территориядәге үләннәрне чабу;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 12 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 8, бу 67% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 8 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең Чишмә торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә, 1 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, "Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизациялэнгэн гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә" һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
-Урам яктырткычларын тоту, яктылык диодлы яктырткычлар сатып алу;
- Ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту: агачларны кистем, үләнне чаптым;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге: юлларны ремонтлау,

юлларны җәй һәм кыш айларында карап тору, юл буендагы территориядәге үләннәрне чабу;

5. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Закирҗанов